**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АТАБАЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422635 Лаишевский район, с. Атабаево
Ул.Молодежная ,д. 1,
Тел, факс: 8(84378)-4-87-41

**АТАБАЙ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

422635 Лаеш районы, Атабай авылы
Яшьлэр урамы , 1нче йорт
Тел,факс: 8(84378)-4-87-41

---

**2025елның 14 ноябре** **12 номер**

# КАРАР

## «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Атабай авыл җирлеге территориясендә пиротехник эшләнмәләрдән файдалану урыны турында» 2019 елның 12 сентябрендәге 12 номерлы Атабай авыл җирлеге башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль законның 30 статьясы һәм «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1993 елның 18 маендагы 1866-XXII номерлы Татарстан Республикасы Законының 25 статьясы, шулай ук «Татарстан Республикасы территориясендә янгынга каршы махсус режим урнаштыру турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 05 декабрендәге 1103 номерлы карары нигезендә, Яңа ел бәйрәм чараларында гражданнарның тормышын һәм сәламәтлеген, физик һәм юридик затларның мөлкәтен, дәүләт яисә муниципаль мөлкәтнең янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү максатларында, карар бирәм:

1. «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Атабай авыл җирлеге территориясендә пиротехника әйберләрен куллану урыны турында» 2019 елның 12 сентябрендәге 12 номерлы, 2019 елның 16 декабрендәге 18 номерлы Башкарма комитет карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның 2 пунктын түбәндәге абзац белән тулыландырырга:

«50 метрдан артык биеклектәге салют һәм фейерверклар үткәргәндә һава киңлеген куллану, шулай ук җир яки су өслегенә һава алымнары полосаларын проекцияләү чикләрендә, салют һәм фейерверклар, биеклекләренә карамастан, Россия Федерациясе һава хәрәкәтен оештыруның бердәм системасы оператив органы рөхсәте белән гамәлгә ашырыла (алга таба - вәкаләтле орган)

. Фейерверк үткәрү өчен вәкаләтле органның рөхсәтен алырга кирәк. Язма рөхсәттән башка муниципаль берәмлек территориясендә фейерверк ясау тыела».
2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында-http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Атабай авыл җирлегенең махсус мәгълүмати стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Р.И. Биләлов